ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 октябрь 2024ел № 7085

Башкарма комитетның «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 декабрендәге 8498 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 декабрендәге 8498 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 16 маендагы 3968 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә»;

2) кушымтага түбәндәге эчтәлектәге 2.5.5, 2.5.6, 2.5.7 пунктлар өстәргә:

«2.5.5. Балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен балигъ булмаган затның гариза бирүче булып торган законлы вәкиле алганда, балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын тормышка ашыру балигъ булмаган затның гариза бирүче булып тормаган законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаган затның законлы вәкиле булып торган гариза бирүче, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта, балигъ булмаган затның балигъ булмаган затка карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алуга вәкаләтле башка законлы вәкиленең фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда), шәхесен таныклаучы документы турындагы мәгълүматларны күрсәтә.

2.5.6. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта, балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга язмача теләк белдергән очракта, балигъ булмаган затка карата

муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре балигъ булмаган затның башка законлы вәкиленә бирелә алмый.

2.5.7. Балигъ булмаган затка карата кәгазь документ рәвешендә рәсмиләштерелгән муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен балигъ булмаган затның гариза бирүче булып тормаган законлы вәкиленә бирү тәртибе, шул исәптән аларны бирү ысуллары һәм сроклары, әлеге бүлекнең 2.5.6 пунктында каралган таләпне исәпкә алып, әлеге Регламентның 3.6.3.1-3.6.3.3 пунктларында билгеләнә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов